*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Наласа гомуми үсеш бирү төрендәге “Балачак” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*



# Чишмә башы

*№ 3*

*Ноябрь , 2025 ел*



***Ата-аналар һәм балалар өчен кызыклы***





## Ноябрь.

Төннәрне озайтып,көннәрне кыскартып,  
Кояш та иртәрәк баядыр.  
Җилләрен,яңгырлы карларын ияртеп  
Хәерлең белән кил, ноябрь .  
Агачлар шәп-шәрә,Уҗымнар яшәрә  
Һәр фасыл үзенчә матур ул.  
Яфраклар бураны,урамны урады  
Ак карлар яуганчы ятыр ул.  
Нур чәчә кояшың,җылылык тоясың  
Син шулай алдыйсың ,ноябрь.  
Чыгасың сөенеп,җәйгечә киенеп  
Аннары яңгырың коядыр.  
Күңелләр моңлана,керфекләр дымлана  
Ник моңсу син шулай ноябрь?  
Яшьлекнең күзләре,күңелдә үзләре  
Онытылмый.Тик белмим каядыр?!  
Игеннәр урылган,барсы да җыелган  
Кирәккән никадәр тырышлык.  
Ә бүген йөрәкләр тели тик теләкләр  
Бир, Раббым ил-көнгә тынычлык,  
Бир, Раббым бары тик тынычлык…



Динә Камалетдинова



## «Бала куркынычсызлыгы-әти-әни җаваплылыгында!»

### «Көз һәм кыш көннәрендә боз өстендә куркынычсызлык кагыйдәләре»

Беренче боз хасил булу белән балаларның хоккей уйнау һәм шугалакта шуу теләге барлыкка килә. Ата-аналар балаларын елга буена караучысыз җибәрмәсеннәр иде. Игътибарлы булу һәм куркынычсызлык кагыйдәләрен төгәл үтәү зарур. Иң беренче һәм иң гади кагыйдә: ихтыяҗ булмаганда боз өстенә кермәгез. Ә керергә туры килсә, салынган сукмаклардан гына йөрегез. Алар булмаганда бозның ныклыгын таяк белән тикшерегез. Бозның катылыгын аяк белән тибеп тикшерергә һич ярамый. Елгаларда су 10 сантиметр калынлыкта катса гына кеше өчен куркыныч булмый. Елга тамакларында, камышлыкларда боз югарак була. Әгәр һава температурасы өч көн дәвамында 0 градустан югарырак тора икән, бозның калынлыгы 25 процентка кими. Бозның калынлыгын гади күз белән дә билгеләп була: зәңгәрсу төстәге боз – ныклы, ак төстәгесе юкарак, соры яисә саргылт булса, ышанычсыз. Әгәр дә боз өстендә бәла-каза чыкса, паникага бирелмәскә, кискен хәрәкәтләр ясамаска кирәк. Әгәр дә, боз ярылып, салкын суга батсагыз, нишләргә? Бу очракта кулларны җәеп, ничек тә булса, бозга башта бер аякны, аннан соң икенчесен күтәреп, шуышып, менәргә кирәк. Әгәр дә боз сезнең авырлыкка чыдаса, әкрен генә ярга таба үрмәләргә була. Кайсы ярдан килгәнсез, шул якка үрмәләргә кирәк, чөнки анда боз тикшерелгән.

Әгәр дә сезнең ярдәм таләп ителсә, нишләргә? Озын таяк, такта, яисә бау табарга кирәк. Йә булмаса шарф, каеш һәм киемнәрне бергә бәйләргә була. Бозга ятып, шушы әйберләр белән бәлагә таручы ягына шуыша башлагыз. Суга батучы янына җитәргә бер-ике метр калгач, туктарга һәм таякны, тактаны яисә бауны сузып, бәлагә таручыны куркыныч зонадан чыгарырга тырышыгыз. Зыян күрүчене коткаргач, җылы урын табып, аның юеш киемнәрен салдырырга, тәнен спирт яисә аракы белән ышкырга, кайнар чәй эчерергә кирәк.

**ЯРАМЫЙ:**

- тиз агымлы, чишмәле, елга кушылдыклары янында боз өстенә керү;
- ярылган боз читенә килү, күпсанлы бәкеләр белән тишкәләнгән боз өслегендә йөрү;

**ЯРЫЙ:**

- кешеләргә боз калынлыгы 7 сантиметрдан да ким булмаганда гына боз өслегенә керү;
- боз калынлыгы 25 сантиметрга җиткәч, гомуми массасы 1,5 тоннаны тәшкил иткән транспорт чараларына елга аша боз кичүләреннән йөрү.








# «Йөрәк җырым,сина,әнием...»

Әнием - иң назлы, яратучан, игелекле, бөтен дөньяда бердәнбер. Балалар бакчасында Әниләр көнен бәйрәм итү яхшы традициягә әверелде, аның төп максаты-мәктәпкәчә яшьтәге балаларда анага каратаярату һәм хөрмәт тәрбияләү, балаларның иҗади сәләтләрен үстерү һәм бәйрәмнең уңайлы, өй атмосферасын булдыру. Бу бәйрәмгә беркем дә битараф кала алмый. Нәкъ менә шуңа күрә безнен балалар бакчасында Әниләр көненә бөтен бала да ныклап әзерләнде. Балалар үз куллары белән әниләренә бүләкләр әзерләделәр. Алар яраткан әниләрен күңелгә үтеп керерлек шигырьләре белән котладылар, назлы һәм матур җырлар җырладылар, күңелле биюләр башкардылар. Әниләр дә читтә калмады, төрле конкурсларда бик теләп катнаштылар. Балалар бакчасы мөдире Эльмира Рашат кызы залда утыручы әниләрне бәйрәм белән котлап, ихлас теләкләрен җиткерде.
Без дә әниләрне чын күнелебездән шушы матур бәйрәмнәре белән котлыйбыз. Сезнен тормышыгыз яхшылык һәм яктылык, мәхәббәт, якыннарыгызның күңел җылысы һәм игътибары белән тулып, йөзләрегез елмаюдан яктырып, нурлар чәчеп торса иде!













## «4 нче ноябрь - Халыклар бердәмлеге көне.»














Бәйрәм уңаеннан балалар бакчасында «Бердәмлектә - безнең көч!» исемле патриотик тәрбия чарасы үткәрелде. Балалар дәүләтебезнең никадәр зур, матур һәм бай булуын белделәр. Дәүләт символлары турында белемнәрен ныгыттылар, халыкларның үзара ничек дус яшәүләре турында сөйләделәр, фикер алыштылар.Төрле милләт кешеләренең иң югары максатларга ирешү өчен берләшүе, Ватанга карата чиксез мәхәббәте һәм ватанпәрвәрлеге илебезгә тарих сынауларын җиңеп чыгарга ярдәм иткән.

## «12 ноябрь - Песнәкләр көне!»

Безнең балалар бакчасында экологик сәгатьләр узды .Песнәкләр көне турында әңгәмә кордык, кошлар турында табышмакларга җаваплар эзләдек,шигырьләр укыдык,төсле кәгазьдән песнәкләр кисеп ябыштырдык.Кошлар безнең дусларыбыз,аларга һәрвакыт ярдәм итеп торырга кирәклеге турында сөйләштек.

Кыш көне балалар песнәкләрне ашатыр өчен җимлекләр ясап элеп куялар. Салкын вакытта алар орлык белән туклаланалар, сөяктән калган итне дә бик яратып чукыйлар, терлек маен ашыйлар. Балаларда табигатькә карата игътибарлы, сакчыл булуны кечкенәдән тәрбияләү бик әһәмиятле.













# «Фән сәгатьләре»

Бүгенге көндә фән һәм технологияләрнең алга китеше, безнең көндәлек тормышта да фән һәм техниканың роле зур урын алып торуы күзәтелә. Шул унайдан безнен балалар бакчасында “Фән сәгатьләре” дайми рәвештә үткәрелеп килә. Әти-әниләр тырышлыгы белән ясалган эшләнмәләрдән күргәзмә, төрле кызыклы тәҗрибәләр, мәктәпкә биология кабинетына мавыктыргыч сәяхәтләр, балаларга фәнни дөньяны ятыртып бара.

Ноябрь аенда мәктәпкә экскурсия булдырылды Балалар биология кабинетына мавыктыргыч сәяхәт ясадылар. Биология фәннәре укытучысы Динә Камил кызы кызыклы һәм мавыктыргыч итеп, балаларга үсемлекләр өчен биологик микроскоп- ул зурайта торган оптик прибор, аның ярдәмендә гади күз белән күренми торган микропредметларны һәм объектлар тикшерүләре турында сөйләде, аңлатты. Балалар үзләре дә бик кызыксынып күзәттеләр, сәяхәт бик файдалы оештырылды.




























# Безнең уңышлар


МБОУ «Многопрофильный лицей имени Г.Курсави» Арского МР РТ
Первичная профсоюзная организация МБОУ «Многопрофильный лицей имени Г.Курсави» Арского МР РТ

ДИПЛОМ

НАГРАЖДАЮТ

Гафурову Эльмиру [illegible]
МБОУ „Наласинская СОШ“

за III место в зональных соревнованиях по настольному теннису среди членов профсоюза учреждений образования Арского муниципального района Республики Татарстан

Директор МБОУ «Многопрофильный лицей имени Г.Курсави» Арского МР РТ — М.З. Ильясов

Председатель первичной профсоюзной организации МБОУ «Многопрофильный лицей имени Г.Курсави» Арского МР РТ — Ч.Х. Гилязиева

Арск – 2025 г.


ГРАМОТА

Государственное автономное профессиональное образовательное учреждение «Арский педагогический колледж имени Габдуллы Тукая»
Муниципальное учреждение «Управление образования» исполнительного комитета Арского муниципального района Республики Татарстан
Муниципальное бюджетное учреждение дополнительного образования «Спортивная школа «Арча» Арского муниципального района Республики Татарстан

награждается

команда
МБДОУ «Наласинский детский сад общеразвивающего вида «Балачак»
(Халиуллин Райнур, Тухбатуллина Саида)
(руководитель Хусаенова Р.Н.)

за III место

в Республиканских спортивных играх «Веселые старты» среди воспитанников дошкольных образовательных учреждений

Директор ГАПОУ «Арский педагогический колледж имени Габдуллы Тукая» — Г.Ф. Гарипова
Начальник МУ «Управление образования» исполкома Арского муниципального района — Н.Н. Муллахметов
Директор МБУ ДО «Спортивная школа «Арча» Арского муниципального района — М.Р. Саляхов

Приказ МУ «Управление образования» №325 от 12.11.2025

20 ноября 2025 года


ҖӘЛИЛ УКУЛАРЫ
ХАЛЫКАРА ӘДӘБИ БӘЙГЕ
МЕЖДУНАРОДНЫЙ ЛИТЕРАТУРНЫЙ КОНКУРС
ДЖАЛИЛОВСКИЕ ЧТЕНИЯ

СЕРТИФИКАТ
УЧАСТНИК

Награждается
ГАЙНУТДИНОВА КАМИЛЯ
ТУХБАТУЛЛИНА САИДА

Руководитель
Шагиева Алсу Курбангалиевна, Гафурова Рафия Ансаровна
МБДОУ"Наласинский детский сад общеразвивающего вида" Балачак" Арского муниципального района Республики Татарстан

Первый заместитель Председателя Национального Совета Всемирного конгресса татар – руководитель Исполнительного комитета Всемирного конгресса татар — Д.Ф. ШАКИРОВ

КАЗАНЬ
2025





***"Татарча диктант" акциясенә кушылдык***

# Туган көн белән котлыйбыз!

Ноябрь аенда кечкенәләр төркеменә йөрүче егетебез Төхфәтуллин Йосыф туган көнен билгеләп үтте. Йосыфка сәламәт, озын гомерле, бәхетле, акыллы, тәүфыйклы булып, әти-әни тигезлегендә үсүен теләп калабыз.







***Газетаны оештыручы һәм баш мөхәррир:*** *Шагиева А.К., Галиуллина А.Ф.*
***Редколлегия әгъзалары****: Гафурова Р.А., Хөсәенова Р.Н, Гафурова Э.Р.*
*Адрес: 422018 ТР,Арча районы, Наласа авылы, Үзәк урам, 76 йорт*